**Татарстан Республикасы**
**Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге составына керүче**
**Әҗмәкәй авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

29 октябрь, 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 5 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе тәзелде:

Әҗмәкәй авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1500 (Бер мең биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II төркем инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, Әфганстанда, Чечняда сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, чернобыльчеләр-ЧАЭСТА авария ликвидаторлары, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар, күп балалы гаиләләр һәм студентлар өчен бер тапкыр түләүне киметергә риза буласызмы? 750 (җиде йөз илле) сум күләмендә әлеге категория гражданнар өчен билгеләргә, алардан суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдереләчәк:

1) юллар төзү, юлларны ремонтлау, вак таш һәм асфальт ватыклары сатып алу, махсус техника хезмәтләре;

2) Әҗмәкәй авылы парклары территориясен төзекләндерү (юлларны реконструкцияләү, урам яктырткычларын, кече архитектура формаларын, коймаларны, балалар уен элементларын сатып алу һәм урнаштыру);

3) технологик тоташтыру, электр материаллары сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру;

4) ясалма юл тигезсезлекләрен төзү буенча эшләрне башкару (ИДН һәм билгеләрне сатып алу һәм урнаштыру);

5) сүүткәргеч проектлау һәм төзү.

Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән хәрби хезмәткә өлешчә мобилизация, РФ Кораллы көчләренә контракт буенча чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взнослар түләүдән азат итәргә.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **1727** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **899** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәлә 894 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **5** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Әҗмәкәй авылы гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. Әҗмәкәй авыл территориясендә яшәү урыны буенча  теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1500 (Бер мең биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II төркем инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, Әфганстанда, Чечняда сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, чернобыльчеләр-ЧАЭСТА авария ликвидаторлары, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар, күп балалы гаиләләр һәм студентлар өчен бер тапкыр түләүне киметергә риза буласызмы?  750 (җиде йөз илле) сум күләмендә әлеге категория гражданнар өчен билгеләргә, алардан суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдереләчәк:

1) юллар төзү, юлларны ремонтлау, вак таш һәм асфальт ватыклары сатып алу, махсус техника хезмәтләре;

2) Әҗмәкәй авылы парклары территориясен төзекләндерү (юлларны реконструкцияләү, урам яктырткычларын, кече архитектура формаларын, коймаларны, балалар уен элементларын сатып алу һәм урнаштыру);

3) технологик тоташтыру, электр материаллары сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру;

4) ясалма юл тигезсезлекләрен төзү буенча эшләрне башкару (ИДН һәм билгеләрне сатып алу һәм урнаштыру);

5) суүткәргеч проектлау һәм төзү

Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән хәрби хезмәткә өлешчә мобилизация, РФ Кораллы көчләренә контракт буенча чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взнослар түләүдән азат итәргә.

мәсәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Әҗмәкәй авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Әҗмәкәй авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы

Г.Т. Хөсәенова